ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ Казан шәһәре Боерык

03.08.2023 № 225- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, дип билгеләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 03 августындагы 225-од номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларына кертелә торган
үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайван төрләрен ябуда асрау һәм табигатькә яңадан кайтару өчен рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 16 маендагы 125-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгында (алга таба – 2018 елның 16 маендагы 125-од номерлы Боерык) (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 388-од номерлы, 2020 елның 12 августындагы 234-од номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 350-од номерлы, 2021 елның 28 октябрендәге 334-од номерлы, 2022 елның 27 сентябрендәге 349-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга;

2018 елның 16 маендагы 125-од номерлы Боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайван төрләрен ябуда асрау һәм табигатькә яңадан кайтару өчен рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Реестр язмасы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булмый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

оешманың исеме яки гариза бирүченең фамилиясе, исеме, этисенең исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификацион номеры, оешманың КПП, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны; физик затның, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы;

әлеге Регламентның 2.8. пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш

тарту өчен нигез;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар датасы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

электрон имза турында мәгълүмат.»;

2.6.2 пунктның икенче абзацында «башкарма хакимият органы» дигән сүзләрне «башкарма хакимият органы» дигән сүзләр белән алыштырырга;

3.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Гариза һәм беркетелгән документлар Комитетка шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта, Республика порталы, КФҮ аша бирелергә мөмкин.

Гариза бирүченең шәхесен билгеләү шәхси кабул итү барышында Россия Федерациясе гражданины паспортын яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесен раслый торган башка документны күрсәтү яисә Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Комитет) идентификацияләү һәм аутентификацияләү аша башкарылырга мөмкин.

Гариза бирүче, гариза һәм документларны электрон формада Республика порталы аша тапшырган очракта, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында авторизация үтә;

Республика порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын (кирәк булганда) электрон гариза формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы куя);

тутырылган электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Гаризаны формалаштыру башка формада өстәмә гариза бирү гаризаның электрон формасын Республика порталында тутыру юлы белән башкарыла (башка формада өстәмә гариза бирү таләп ителми).

Гариза бирүчегә гариза язганда түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

а) гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклау

мөмкинлеге;

б) электрон гариза формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

в) элек электрон гариза формасына кертелгән кыйммәтләрне кулланучы теләге белән теләсә кайсы вакытта, шул исәптән кертү хаталары килеп чыкканда һәм белдерүнең электрон формасына кыйммәтләрне яңадан кертү өчен кире кайтарганда саклау;

г) гариза бирүче ЕСИАда урнаштырылган мәгълүматны һәм, ЕСИАда булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә Республика порталында басылган мәгълүматларны кулланып мәгълүматны керткәнче, гаризаның электрон формасы кырын тутыру;

д) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

е) гариза бирүченең Республика порталында үзенең элек биргән гаризаларына кимендә бер эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга кимендә 3 ай эчендә керү мөмкинлеге.

КФҮ аша гариза биргән очракта:

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирә һәм документларны әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә КФҮгә тапшыра.

Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, КФҮ белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, КФҮ белгече гариза бирүченең кабул ителгән һәм теркәлгән документларын КФҮнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедуралар КФҮнең эш регламенты һәм Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү белән билгеләнгән вакытта, ләкин КФҮдә гаризаны теркәгәннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән гариза яки документлар кабул итүдән баш тарту.»;

3.6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3.1. Кирәк булган очракта, Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Россия Федерациясе субъектының әлеге мәсьәләне хайваннарның мондый төрләренең килеп чыккан урынында күзәтүче башкарма хакимият органына электрон формада Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган

хайван һәм үсемлек төрләренең килеп чыгышының законлылыгын раслый торган документлар (мәгълүматлар) бирү турындагы сорату формалаштыра һәм җибәрә.

Сорату җибәрү өчен гариза бирүченең теркәлгән гаризасы нигез булып тора.

Ведомствоара мәгълүмати сорату, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында, күрсәтелгән органнарга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны һәм гаризага кушылган документларны теркәү көнендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (мәгълүмат) бирү турында соратулар.

3.6.3.2. Ведомствоара соратулар буенча Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) бу документлар электрон формада алар карамагында булган органнар тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләре, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара сорату җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә.

3.6.3.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарылырга мөмкин:

1) соратыла торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә электрон ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра алмаганда;

2) ведомствоара сорату җибәргәндә, кәгазьдә документларның төп нөсхәсен тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара соратуларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты ведомствоара сорату кергән көннән биш эш көненнән артып китә алмый.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы вәкаләтле затка җибәрелгән сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) яки баш тарту турында хәбәрнамәне алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карарлар кабул итү тора.»;

Регламентның 2 нче кушымтасында «Ф.И.А.» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентның 4 нче кушымтасында «физик затның атасының исеме» сүзен «физик затның атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга,

«Ф.И.А.» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентның 5 нче кушымтасында «физик затның атасының исеме» сүзен «физик затның атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга, «Ф.И.А.» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентның 6 нчы кушымтасында «физик затның Ф.И.А. (булган очракта)» сүзләрен «физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга, «Ф.И.А.» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләре белән алыштырырга;

Регламентның 7 нче кушымтасында «физик затның Ф.И.А. (булган очракта)» сүзләрен «физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга, «Ф.И.А.» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләре белән алыштырырга.

2. «Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2018 елның 16 маендагы 126-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгында (алга таба – 2018 елның 16 маендагы 126-од номерлы Боерык) (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге  344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге  389-од номерлы, 2020 елның 12 августындагы232-од номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге  350-од номерлы, 2021 елның 12 августындагы  235-од номерлы, 2021 елның 23 сентябрендәге  287-од номерлы, 2022 елның 02 декабрендәге 405-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга;

2018 елның 16 маендагы 126-од номерлы боерык белән расланган Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча регламент):

2.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Реестр язмасы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булмый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

оешманың исеме яки гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме

(булган очракта), салым түләүченең идентификацион номеры, оешманың КПП, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны; физик затның, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы;

әлеге Регламентның 2.8.2 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар датасы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

электрон имза турында мәгълүмат.»;

2.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

1. Билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле хезмәтләр һәм документлар бирү турында сорату бирү;

2. 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү.»;

5.3 пунктның 5.3 икенче абзацында «соңгысы – булган очракта» сүзләрен «булган очракта» сүзләре белән алыштырырга;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт

ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ АЕРУЧА САКЛАУЛЫ ТАБИГЫЙ ТЕРРИТОРИЯЛӘРДӘГЕ, ШУЛАЙ УК РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ КЫЗЫЛ КИТАБЫНА КЕРТЕЛГӘН ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫННАН ТЫШ, ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫН КУЛЛАНУГА _____ НОМЕРЛЫ РӨХСӘТ

Бирелде:

______________________________________________________________________

(оешманың, шәхси эшкуарның исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Куллану рөхсәт ителә: ______________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Түбәндәге төрләрдәге хайваннар дөньясы объектларын куллану өчен:

| Хайваннар дөньясы объектлары исемлеге (русча һәм латинча исеме) | Саны | Файдаланырга планлаштырыла торган хайваннар дөньясы объектларының җенесе, яше |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Хайваннар дөньясы объектларын куллану урыны: ____________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану вакыты: ____________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану максаты: ___________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану алымнары: __________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану кораллары: _________________________

Рөхсәтне башка затларга биреп тору тыела.

Рөхсәт гамәлдә булу вакыты тәмамлангач, аны куллану турында хисап белән ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Бирү датасы: _________________

Рәис _________________________________»;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 2 нче кушымтасында «шәхси эшкуарлар: Ф.И.А.» сүзләрен «шәхси эшкуарлар: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән, «(Ф.И.А.» сүзләрен «(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 3 нче кушымтасында «шәхси эшкуарлар: Ф.И.А.» сүзләрен «шәхси эшкуарлар: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән, «(Ф.И.А.» сүзләрен «(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 4 нче кушымтасында «шәхси эшкуарлар: Ф.И.А.» сүзләрен «шәхси эшкуарлар: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган

очракта)» сүзләре белән, «(Ф.И.А.» сүзләрен «(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ АЕРУЧА САКЛАУЛЫ ТАБИГЫЙ ТЕРРИТОРИЯЛӘРДӘГЕ, ШУЛАЙ УК РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ КЫЗЫЛ КИТАБЫНА КЕРТЕЛГӘН ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫННАН ТЫШ, ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫН КУЛЛАНУГА _____ НОМЕРЛЫ ГАРИЗА

Гариза бирүче турында белешмәләр:
________________________________________________________________________
(юридик затлар өчен – оешманың тулы исеме,
________________________________________________________________________
банк реквизитлары, адресы, элемтә өчен телефоны; физик
________________________________________________________________________
затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта),
________________________________________________________________________
паспорт мәгълүматлары, адресы, элемтә өчен телефоны)

Хайваннар дөньясы объектларын куллану максаты: ______________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану вакыты: ______________________

Файдаланырга планлаштырыла торган хайваннар дөньясы объектлары исемлеге: _____________

Файдалану өчен хайваннар дөньясы объектлары саны (төрләре буенча): ________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
_______________________

Хайваннар дөньясы объектларының җенси һәм яше буенча составы (билгеләү мөмкинлеге булган очракта): ______________________________________________

Хайваннар дөньясы объектларын файдалану территориясе (акваториясе): ________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану алымнары: ________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану кораллары: _______________________

Файдаланыла торган хайваннар дөньясы объектларын тоту шартлары турында белешмәләр:_______________________________________________________________

____________________________________________________________________

Рөхсәттән файдалануга җаваплы зат: _____________________________________

____________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануда катнашучы затлар исемлеге: ____________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте Идарәсеннән _________ елның ___ _____ ____ номерлы белешмәләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч юк (бар) __________________________________________

(дата)

____________________________________________________________________

(кирәклесенең астына сызарга)

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза

___________________________ _______________________________________

(гариза бирүче затның имзасы)..... (гариза бирүче затның фамилиясе һәм инициаллары)

Дата: «___» _____________ 20____»;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 6 нчы кушымтасында «(Ф.И.А.)» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән, «шәхси эшкуарларның: Ф.И.А.» сүзләрен «шәхси эшкуарларның: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 7 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
кемнән:

___________________________________

___________________________________
(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (буллган очракта), адресы (почта һәм (яки) электрон); юридик затлар өчен: оешманың исеме, адресы (почта һәм (яки) электрон)

ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ АЕРУЧА САКЛАУЛЫ ТАБИГЫЙ ТЕРРИТОРИЯЛӘРДӘГЕ, ШУЛАЙ УК РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ КЫЗЫЛ КИТАБЫНА КЕРТЕЛГӘН ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫННАН ТЫШ, ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫН КУЛЛАНУГА РӨХСӘТНЕ ФАЙДАЛАНУ БУЕНЧА ХИСАП

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт гамәлдә булган чорда түбәндәге төрләр тотылды, саны: ________________________________

Дата _______________ ____________________________________ _______________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)(имза)»;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 8 нче кушымтасында «шәхси эшкуарлар: Ф.И.А.» сүзләрен «шәхси эшкуарлар: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән, «(Ф.И.А.» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Рөхсәт бирү буенча Регламентның 9 нчы кушымтасында «(Ф.И.А.)» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән, «шәхси эшкуарларның: Ф.И.А.» сүзләрен «шәхси эшкуарларның: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга.

3. «Махсус саклanyла торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 16 маендагы 127-од номерлы боерыгында (алга таба – 2018 елның 16 маендагы 127-од номерлы

Боерык) (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од, 2019 елның 12 декабрендәге 390-од, 2020 елның 16 ноябрендәге 349-од, 2021 елның 30 сентябрендәге 300-од номерлы, 2022 елның 26 маендагы 122-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга;

2018 елның 16 маендагы 127-од номерлы боерык белән расланган Махсус саклана торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба - Хайваннар дөньясы объектларын тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча регламент)

2.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Реестр язмасы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булмый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

оешманың исеме яки гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), салым түләүченең идентификацион номеры, оешманың КПП, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны; физик затның яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы;

әлеге Регламентның 2.8. пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

электрон имза турында мәгълүмат.»;

2.6.2 пунктында:

1 пунктчаны (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе) сүзләре белән тулыландырырга;

2 пунктчаны (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе) сүзләре белән тулыландырырга;

3.3.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

Гаризаны формалаштыру башка формада өстәмә гариза бирү гаризаның электрон формасын Республика порталында тутыру юлы белән башкарыла (башка

формада өстәмә гариза бирү таләп ителми).

Гариза бирүчегә гариза язганда түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

а) гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

б) электрон гариза формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

в) элек электрон гариза формасына кертелгән кыйммәтләрне кулланучы теләге белән теләсә кайсы вакытта, шул исәптән кертү хаталары килеп чыкканда һәм белдерүнең электрон формасына кыйммәтләрне яңадан кертү өчен кире кайтарганда саклау;

г) гариза бирүче ЕСИАда урнаштырылган мәгълүматны һәм, ЕСИАда булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә Бердәм порталда, Республика порталында басылган мәгълүматларны кулланып мәгълүматны керткәнче, гаризаның электрон формасы кырын тутыру;

д) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

е) гариза бирүченең Республика порталында үзенең элек биргән гаризаларына кимендә бер эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга кимендә 3 ай эчендә керү мөмкинлеге.

3.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү.

Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан (гариза бирүчеләр –юридик затлар өчен) өземтә бирү турында; шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан (гариза бирүчеләр – шәхси эшкуарлар өчен) өземтә бирү турында Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә электрон формада соратулар төзи һәм җибәрә.

Сорату җибәрү өчен гариза бирүченең теркәлгән гаризасы нигез булып тора.

Ведомствоара мәгълүмати сорату, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында, күрсәтелгән органнарга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны һәм гаризага кушылган документларны теркәү көнендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (мәгълүмат) бирү турында соратулар.

Ведомствоара соратулар буенча Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) бу документлар электрон формада алар карамагында булган органнар тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләре, шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның тәкъдим ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым

нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә тиешле ведомствоара сорату җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмыйча бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазьдә башкарылырга мөмкин:

1) соратыла торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә электрон ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра алмаганда;

2) ведомствоара сорату җибәргәндә, кәгазьдә документларның төп нөсхәсен тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.2 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^2$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара соратуларга җавап әзерләү һәм җибәрү вакыты ведомствоара сорату кергән көннән биш эш көненнән артып китә алмый.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара соратулар җибәрү өчен җаваплы вәкаләтле затка җибәрелгән сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) яки баш тарту турында хәбәрнамәне алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай законнарны һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карарлар кабул итү тора.»;

Махсус сакланыла торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү регламентына 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус сакланыла торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентна 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты

420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт

Махсус сакланыла торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә _________ номерлы

РӨХСӘТ

Бирелде ______________________________________________________________

(исеме (тулы һәм кыскартылган), оештыру-хокукый рәвеше, юридик затның урнашу урыны яки шәхси эшкуарның (физик затның) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шәхесен таныклаучы документ белешмәләре)

Эшчәнлек төрләре: (ярым ирекле шартларда, ясалма яшәү шартларында тоту һәм (яки) үрчетү) ____________________________________________________________

______________________________________________________________________

(кирәклесен күрсәтергә)

хайваннар дөньясы объектлары ... _____________________________________

(аучылык ресурсларының русча һәм латинча атамалары ,

______________________________________________________________________

асрауга һәм үрчетүгә планлаштырыла торган хайваннарның санын һәм җенесен күрсәтеп)

максаты: ______________________________________________________

(максатын күрсәтергә)

Асрау шартлары: ________________________________________________

(ярым ирекле тоту өчен күздә тотыла торган территорияләр чикләре һәм мәйданы, ясалма

______________________________________________________________________

төзелгән яшәү тирәлегендә тоту өчен билгеләнгән объектларның тасвирламасы һәм адресы)

Заказчыга хайваннар дөньясы объектларын китерү яки аларны яшәү тирәлегендә урнаштыру шартлары

______________________________________________________________________

(транспорт төре, яшәү тирәлегендә урнаштырырга планлаштырыла торган хайваннар дөньясы объектлары саны)

Хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегендә урнаштыру тәртибе

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(хайваннар дөньясы объектларын табигый яшәү тирәлегенә чыгаруга планлаштырыла торган төрләр һәм аларның саны һәм чыгаруның планлаштырылган вакытлары)

Рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты: «__» ________ 20__ елдан «__» ________ 20__ елга кадәр

Рөхсәтне бирде ____________________________________________________________

(рөхсәт биргән затның фамилиясе, инициаллары һәм вазыйфасы)

_________________ _____________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

Рөхсәт бирү датасы: «__» ________ 20__ ел

М.У.

«__» ________ 20__ ел» ________________

(имза)»;

Махсус саклана торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү регламентына 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус саклана торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентна 2 нче кушымта

Форма

Кемгә: ______________________________

(физик затның, шәхси эшкуарның фамилиясе,

__________________________________

исеме, атасының исеме (булган очракта)

__________________________________

/юридик затның атамасы)

Баш тарту турында хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты
___________________________________________________________

(оешма исеме, ИНН/КПП, ОГРН, урнашу урыны,
___________________________________________________________

физик затның/шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы)
___________________________________________________________

Рөхсәт бирүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Баш тарту сәбәбе: ___________________________________________

_________________ _________________ ________________________

(вазыйфасы) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)»;

Махсус саклanyла торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү регламентына 3 нче кушымтада «Ф.И.А. (булган очракта)» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга, «атасының исеме (соңгысы – булган очракта)» сүзләрен «атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Махсус саклана торган федераль әһәмияттәге табигый территорияләрдә булган хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәттән тыш, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) тотуга һәм үрчетүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү регламентына 4 нче кушымтада «физик затлар өчен: Ф.И.А.» сүзләрен «физик затлар/шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләре белән алыштырырга.

4. «Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 16 маендагы 128-од номерлы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгында (алга таба – 2018 елның 16 маендагы 128-од номерлы боерык) (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 391-од номерлы, 2020 елның 12 августындагы 229-од номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 350-од номерлы, 2021 елның 27 октябрендәге 311-од номерлы, 2022 елның 15 сентябрендәге 336-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән):

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алыштырырга;

2018 елның 16 маендагы 128-од номерлы Боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Реестр язмасы дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булмый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

Оешманың исеме яки гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы – булган очракта), салым түләүченең идентификацион номеры, оешманың КПП, төп дәүләт теркәү номеры, урнашу урыны; физик затның, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта), паспорт мәгълүматлары, теркәлү адресы

әлеге Регламентның 2.8.2 пункты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар датасы;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса);

электрон имза турында мәгълүмат.»;

3.3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Гариза һәм беркетелгән документлар Комитетка шәхсән, ышанычлы зат, почта, электрон почта, Республика порталы, Бердәм портал, КФҮ аша бирелергә мөмкин.

Гариза бирүче гариза һәм документларны электрон формада Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында, Бердәм порталда авторизация үтә;

Республика порталында, Бердәм порталда электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын (кирәк булганда) электрон гариза формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы куя);

тутырылган электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп (гади электрон имза һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Гаризаны формалаштыру башка формада өстәмә гариза бирү гаризаның электрон формасын Бердәм порталда, Республика порталында тутыру юлы белән башкарыла (башка формада өстәмә гариза бирү таләп ителми).

Төзелгән гаризага формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Гаризаның электрон формасының дөрес тутырылмаган кыры Бердәм портал тарафыннан ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны электрон рәвештә гаризаның электрон формасында ук төзәтү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.

Гариза бирүчегә гариза язганда түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

а) гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

б) электрон гариза формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

в) элек электрон гариза формасына кертелгән кыйммәтләрне кулланучы теләге белән теләсә кайсы вакытта, шул исәптән кертү хаталары килеп чыкканда һәм белдерүнең электрон формасына кыйммәтләрне яңадан кертү өчен кире кайтарганда саклау;

г) гариза бирүче ЕСИАда урнаштырылган мәгълүматны һәм, ЕСИАда булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә Бердәм порталда, Республика порталында басылган мәгълүматларны кулланып мәгълүматны керткәнче, гаризаның электрон формасы кырын тутыру;

д) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

е) гариза бирүченең Бердәм порталда, Республика порталында үзенең элек биргән гаризаларына кимендә бер эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларга кимендә 3 ай эчендә керү мөмкинлеге.

КФҮ аша гариза биргән очракта:

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирә һәм документларны әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә КФҮгә тапшыра.

Гаризалар кабул итүче КФҮ хезмәткәре КФҮнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, КФҮ белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, аңа документларны кире кайтара (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта).

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, КФҮ белгече гариза бирүченең кабул ителгән һәм теркәлгән документларын КФҮнең эш регламентында билгеләнгән тәртиптә Комитетка җибәрә. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. КФҮ аша гариза биргән очракта, әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедуралар КФҮнең эш регламенты һәм Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү белән билгеләнгән вакытта, ләкин КФҮдә гаризаны теркәгәннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Комитетка җибәрелгән гариза яки документлар кабул итүдән баш тарту.»;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Регламентының 2 нче кушымтасында «физик затның Ф.И.А. (булган очракта)» сүзләрен «физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга, «Ф. И. А. (булган очракта)» сүзләрен «фамилиясе, исем, әтисенең исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Регламентының 4 нче кушымтасында «физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләрен «физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга, «Ф. И. А. (булган очракта)» сүзләрен «фамилиясе, исем, әтисенең исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләр төрләренең әйләнешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының 5 нче кушымтасында «Ф.И.А.» сүзләрен «фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы астында булган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Регламентының 6 нчы кушымтасында «физик затның Ф.И.А. (булган очракта)» сүзләрен «физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга, «Ф. И. А. (булган очракта)» сүзләрен «фамилиясе, исем, әтисенең исеме (булган очракта)» сүзләре белән алыштырырга».